КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 7 сентябрь г.Казань № 801

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итү характерында (ирекле) теркәү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 5 май, 298 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итү характерында (ирекле) теркәү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итү характерында (ирекле) теркәү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 5 май, 298 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 август, 629 нчы; 2020 ел, 16 май, 396 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итү характерында (ирекле) теркәү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Этне теркәүгә алу турындагы гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

эт хуҗасының паспорт күчермәсе (граждан өчен) яки юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе (юридик зат өчен);

салым түләүченең тәңгәлләштерү номерын күрсәтеп, гариза бирүчене салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

гариза бирүченең физик зат – эт хуҗасы (граждан өчен) исеменнән эш итүгә вәкаләтен раслый торган документ;

гариза бирүченең юридик зат – эт хуҗасы (юридик затлар өчен) исеменнән эш итүгә вәкаләтен раслый торган документ эш итәргә;

эткә милек хокукы яки башка әйбер хокукы булуын раслый торган документ (булганда);

этнең элегрәк төшерелгән тәңгәлләштерү чаралары булуы турында мәгълүмат (булганда);

эткә карата үткәрелгән мәҗбүри профилактика ветеринария чаралары турында мәгълүмат (булганда);

эш баласына метрика яки эт шәҗәрәсенең күчермәсе (булганда);

этнең фотосурәте (эт хуҗасының теләге буенча).

Эт хуҗасы үз инициативасы белән гражданның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм мәҗбүри башка түләүләр буенча бурычлары булмавы турында белешмә кәгазен бирергә хокуклы. Әгәр дә әлеге документ эт хуҗасы тарафыннан үз инициативасы белән тапшырылмаса, Ветеринария өлкәсендәге вәкаләтле орган яки ведомство буйсынуындагы оешма аны салым органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.»;

17 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Дубликат бирү турындагы гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

эт хуҗасының паспорт күчермәсе (граждан өчен) яки юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе (юридик зат өчен);

салым түләүченең тәңгәлләштерү номерын күрсәтеп, гариза бирүчене салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

гариза бирүченең физик зат – эт хуҗасы (граждан өчен) исеменнән эш итүгә вәкаләтен раслый торган документ;

гариза бирүченең юридик зат – эт хуҗасы (юридик затлар өчен) исеменнән эш итүгә вәкаләтен раслый торган  документ эш итәргә;

эткә милек хокукы яки башка әйбер хокукы булуын раслый торган документ (булганда);

этне теркәү турындагы яраксыз булган таныклык (булганда).

Эт хуҗасы үз инициативасы белән гражданның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм мәҗбүри башка түләүләр буенча бурычлары булмавы турында белешмә кәгазен бирергә хокуклы. Әгәр дә әлеге документ эт хуҗасы тарафыннан үз инициативасы белән тапшырылмаса, Ветеринария өлкәсендәге вәкаләтле орган яки ведомство буйсынуындагы оешма аны салым органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.»;

21 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Этне теркәү турындагы таныклыкны алыштыру турындагы гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

эт хуҗасының паспорт күчермәсе (граждан өчен) яки юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе (юридик зат өчен);

салым түләүченең тәңгәлләштерү номерын күрсәтеп, гариза бирүчене салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

гариза бирүченең физик зат – эт хуҗасы (граждан өчен) исеменнән эш итүгә вәкаләтен раслый торган документ;

гариза бирүченең юридик зат – эт хуҗасы (юридик затлар өчен) исеменнән эш итүгә вәкаләтен раслый торган  документ эш итәргә;

эткә милек хокукы яки башка әйбер хокукы булуын раслый торган документ (булганда).

Эт хуҗасы үз инициативасы белән гражданның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм мәҗбүри башка түләүләр буенча бурычлары булмавы турында белешмә кәгазен бирергә хокуклы. Әгәр дә әлеге документ эт хуҗасы тарафыннан үз инициативасы белән тапшырылмаса, Ветеринария өлкәсендәге вәкаләтле орган яки ведомство буйсынуындагы оешма аны салым органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.»;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин